

**/Безнең бәйрәмнәр/**

### *Яңа ел тамашалары*

II чирек, гадәттәгечә, Яңа елны каршы алу кичәләре белән тәмамлана. Быел да чыршы бәйрәменә ныклап әзерләнделәр. Иң элек залыбызны газеталар, плакатлар, төрле эшләнмәләр белән бизәдек. Зал уртасына матур чыршыбыз да куелгач, бөтенләй әзерләнеп беткәнлегебез күренә инде. Ә үзебезгә килгәндә, безне сыйныф җитәкчеләребез күлмәкләр тегеп тә, уен өчен кирәк булган кулланмаларны табып та, бар тырышлыкларын куеп әзерләделәр. Бәйрәмгә ямь өстәп, Рафик абый олимпиадаларда җиңүчеләргә, отличникларга, төрле конкусларда урын алучыларга мактау кәгазьләре өләште.

Яңа ел бәйрәме һәр елны үзенчәлекле сценарий буенча алып барыла. Быел без сыйныфташым Камил белән юлбасарлар булып, Яңа елга килергә комачауларга тырыштык. Тик ахырдан Убырлы белән үзебезнең начар эшләребезгә үкендек. Убырлы булып Карина апа бик оста уйнады. Кар кызыбыз Кәүсәр бик матур җыр белән тамашачыларны котлады. Кыш бабай да бик шаян иде. Илсур абый гел шундый оста инде ул. Кечкенә балаларга тирән төпле капчыгыннан тәмле конфетлар өләште. Миңа башлангычта укучы малайларның Аждаһа киемендә



биюләре бик ошады. Бар да бер төрле костюмнан булгач, биюләр бигрәк матур була шул. “Кар бөртекләре” биюе дә тамашачылар күңеленә хуш килде.

Ә кичке чыршы бәйрәмендә 7 нче һәм 11 нче сыйныфлар катнашты. Алар номерлар гына әзерләмичә, тәмле өстәлләр артында утырып каршы алдылар Яңа елны. Матур тамашалары арасында Серле Санта да уткәрделәр. Лоторея уеннары да уйнаттылар. Иң ахырдан, һәрвакыттагыча, дуслык җырлары яңгырады.

Яңа ел беркайчан да бүләксез булмый. Безгә, һәр балага, район хакимияте тарафыннан Кыш бабай пакетлары өләштеләр. Бәйрәмне әзерләүче барлык апаларга рәхмәт әйтеп калам.

***Ләйсән Закирова, VIсыйныф укучысы***

**/Безнең спорт/**

### *Фаил республика чемпионатында*

Ир-атлар һәм хатын-кызлар арасында классик шахмат буенча Татарстан Республикасы чемпионаты тәмамланды. Ярышлар 8-17 декабрьдә Татарстанның Р.Г.Нәҗметдинов исемендәге шахмат федерациясендә үтте. Турнирда Казан, Чаллы, Яшел Үзән, Әлмәт, Түбән Кама, Лениногорск, Бөгелмә, Алабуга, Чистай, Актаныш, Кукмара, шулай ук, Әтнә, Аксубай, Азнакай, Биектау һәм Питрәч районнары шахматчылары катнашты. Уен 9 турда үтте. Шахматчылар төрле яшьтә булуга карамастан, уеннар швецар системасы буенча оештырылган иде. Әлеге турнирда безнең яшь, ләкин тәҗрибәле шахматчыбыз **Фаил Гафиятуллин** да көч сынашты. Нәтиҗәдә, Фаил авыл җирлеге ир - атлары категориясендә II урынга лаек булды. Аны әлеге югары нәтиҗәсе белән котлыйбыз, киләчәктә зуррак үрләр яулавын телибез.

### *Көрәш батырларыбызның җиңүләре*



Норлат шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессының татар спортчылары берлеге ярдәмендә бишенче тапкыр Рәис Һадиев истәлегенә багышланган билбау көрәше буенча ярышлар узды. Безнең көрәшче егетләребез **Камалов Илнур** 35 кг авырлыкта II урын, **Сагдиев Рәмзис** 32 кг авырлыкта II урын, **Шичкин Али** 45 кг авырлыкта III урыннарны яуладылар.

23 нче декабрьдә дә Чистай шәһәрендә Гимадиевлар призына уздырган көрәштә шул ук егетләребез уңыш казанды. **Сәгдиев Рәмзис** I урынны, **Замалетдинов Зөлфәт** II урынны алдылар. **Камалов Илнур** белән **Хәбибрахманов Абдулла** III урынны бүлештеләр. Батыр егетләребезгә киләчәк бәйгеләрдә дә зур уңышлар теләп калабыз.

**/Котлыйбыз!/**



Декабрь аенда дөньяга килгән дустыбыз **Гафиятуллина Руфинәне** (II сыйныф) туган көне белән котлап, ныклы сәламәтлек, укуында зур уңышларга ирешүләрен телибез.

Мәктәпнең техник хезмәткәре **Хәтмәтдинова Рәхилә апаны** да гомер бәйрәме белән котлап, тормыш иминлеге, ныклы исәнлек теләп калабыз.


**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Тәхвәтуллин



# Мәктәп хәбәрчесе

Түбән Майна урта мәктәбе газете

Тел. 8 (84344)4-38-46 sch1644maina@mail.ru

№10 (№51) декабрь 2023 ел


**/Мөхәррир минбәре/**



### *Мәктәптә – республикакүләм фәнни-гамәли конференция*

9 нчы декабрь көнне мәктәбебездә **“Татар халкының мәдәни мирасын өйрәнү, саклау һәм яшь буынга җиткерү мәсьәләләре”** дип аталган фәнни-гамәли конференция булып узды. Бу чара район җитәкчелеге тәкъдиме белән, “Укытучылар һәм остазлар елы” һәм “Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы” буларак игълан ителгән 2023 нче елгы чараларны йомгаклау максатыннан уздырылды. Бу мәртәбәле җыенның төп мәгънәсе - яшь буынны милләт вәкиле буларак тәрбияләүнең төрле юлларын барлау, һәм шушы юнәлештә гамәл кылучыларның эш тәҗрибәсе белән танышудан гыйбарәт иде.

Республикакүләм дәрәҗәдә оештырылганга, чакырылучылар Татарстанның төрле төбәкләреннән килде. Көн бик салкын булу сәбәпле, теркәлгән катнашучыларның шактый өлеше килә алмады. Конференциядә Казаннан, Чаллыдан, Алабугадан, Болгардан зур галимнәр һәм күренекле язучыларның килүе чарабызның дәрәҗәсен билгеләде, ә биредә алар күп иде! Тарих фәннәре докторлары – Фаяз Хуҗин, Фәйзелхак Ислаев, Дамир Исхаков. Дистәләгән фән кандидаты – Җәмил Мөхәммәтшин, Альберт Нигамаев, Фәүзия апа Бәйрәмова, Нурулла Гариф, Зөфәр Шакиров, Гөлүсә Закирова, Галим Хисамиев, Гүзәл Батыршина, Радик Сабиров һәм башкалар... Моның өстенә Казаннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе җитәкчесе Илгиз Халиковның һәм Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе урынбасары Равил хәзрәт Зөфәровның, Аксубай районы башкарма комитеты җитәкчелегенең дә катнашуы фәнни җыенның абруен тагы да күтәреп җибәрде. Конференция эшендә төрле авыллардан музей җитәкчеләре, ана теле һәм тарих укытучылары, балалар бакчалары тәрбиячеләре, дин һәм мәдәният әһелләре катнашты. Катнашучыларның чагыштырмача күпчелеге үзебезнең Аксубай районыннан булса да, җыенның географиясе Чистай, Яңа Чишмә, Алексеевск, Әлки, Балык Бистәсе, Түбән Кама, Питрәч районнары, Казан, Чаллы, Алабуга һәм Болгар шәһәрләре исәбенә шактый киңәйде. Гомумән алганда, катнашучылар саны 100дән артык иде.



Милли ризыклардан сыгылып торган өстәлләр артында чәйләп алганнан соң, кунаклар бернечә мастер-класста шамаил ясау, чигеш чигү, колмак чүпрәсеннән икмәк салу, тавык тутыру, өчпочмак пешерү ысуллары белән таныштылар. Мәктәп укучыларының сәнгать эшләнмәләре күргәзмәсен карадылар. Пленар утырышны укучы кызларыбыздан торган мөнәҗәтчеләр төркеме мәшһүр якташыбыз, болгар-татар әдәбиятына нигез салучылардан булган Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәрен көйләп башкару белән башлап җибәрде. Алардан соң татар халкының мәдәни мирасын өйрәнү, саклау һәм яшь буынга җиткерү буенча күп хезмәтләр башкарган затларга Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Диния нәзарәте, Татарстан китап нәшрияты, Болгар тарихи тыюлыгы, Аксубай районының рәхмәт хатлары тапшырылды.

Конференциядә катнашучылар пленар утырышта чыгыш ясаган галимнәрне зур кызыксыну белән тыңладылар. Төшке аштан соң җыенның эше секцияләрдә дәвам итте. Секцияләр **«Балалар бакчысында һәм башлангыч сыйныфларда милли мохит булдыруга кагылышлы мәсьәләләр», «Яңа белем бирү стандартлары кертелү шартларында туган телне укытуга кагылышлы мәсьәләләр», «Мәдәни мирасыбызның төрле юнәлешләре», «Туган як тарихын өйрәнү тәҗрибәсе», «Дини мәгарифкә кагылышлы мәсьәләләр»** юнәлешләре буенча алып барылды. Конференция барышында әйтелгән тәкъдимнәр җыенның йомгаклау өлешендә кабул ителгән резолюциягә кертелде.

Конференция эшен мәгълүмати яктан яктырту буенча да зур эш башкарылды. Җыенда катнашучыларның алдан җибәрелгән материаллары буеча алдан ук җыентык бастырылган иде. Конференция эше телезмага төшерелеп ТНВ каналыннан “Татарлар” тапшыруында күрсәтелде. Чараның барышы һәм әһәмияте турындагы киң күләмле язмалар “Мәдәни җомга”, “Безнең гәҗит” газеталарында һәм интернет сайтларында чыгарылды. Чыгыш ясаучылар барысы да конференция эшенә генә түгел, безнең мәктәпнең эшчәнлегенә дә зур бәя бирделәр.

***Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир***

***/Рәсми хәбәрләр/***

## *Яртыеллык нәтиҗәләре*

Бу чирек мәктәп укучылары һәм укытучылар өчен киеренке, тыгыз шартларда узды. Беренчедән, яртыеллык билгеләр чыгарыла, икенчедән, олимпиадалар чоры. Бу шартлар өстәмә әзерләнүне таләп итә, шуның өстенә Яңа ел бәйрәмнәрен дә тиешле дәрәҗәдә уздырырга кирәк.

Фән олимпиадаларының район туры буенча түбәндәге нәтиҗәләргә ирешелде:

- биологиядән һәм математикадан **Гафиятуллин Фаил** (VII сыйныф) – призер;
- татар теленнән **Нурматова Асия**(IV сыйныф), **Закирова Ләйсән** (VI сыйныф) – җиңүчеләр, **Гафиятуллин Самат, Нурматова Зәйнәп** (X сыйныфлар) – призерлар;
- татар әдәбиятыннан **Нурматова Зәйнәп**– җиңүче,**Гафиятуллин Самат** – призер (X сыйныфлар).

Шулай ук, рәсем һәм төрле эшләнмәләр конкурсларында актив катнашучы укучысы **Хәйруллин Мансур** (I сыйныф),**Нурматова Асия** (IV сыйныф)– җиңүчеләр,**Сафиуллина Гөлсем** (III сыйныф), **????** (VI сыйныф)– призерлар булдылар.

Чирек билгеләре буенча мәктәп укучыларының белем сыйфаты **65%** тәшкил итте. Отличниклар – **Гафиятуллина Руфинә** (II сыйныф), **Закиров Инсаф** белән **Камалов Илнур** (III сыйныфлар),**Нурматова Асия** (IV сыйныф),**Закирова Ләйсән** (VI сыйныф**), Гафиятуллин Фаил** (VII сыйныф).

***Илдар Хәбибуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары***

***/Мәктәп тормышы/***

## *Билгесез солдат көне*

Рәсәй тарихында чагыштырмача яңа истәлекле бу дата ел саен 3 декабрьдә билгеләп үтелә. Бу көн сугыш кырларында ятып калган һәм исемнәре билгесез булган Советлар Союзы һәм Рәсәй сугышчылары турындагы хәтерне, аларның хәрби батырлыгын мәңгеләштерүгә юнәлтелгән.



Илебездә Билгесез солдат көне беренче тапкыр 2014 нче елда билгеләп үтелде. 3 нче декабрь көне очраклы гына сайланмаган. Нәкъ менә шул көнне, 1966 елның 3 декабрендә, Мәскәү янында немец-фашист гаскәрләренең тар-мар ителүенә 25 ел тулу уңаеннан Ленинград шоссесының 41нче чакрымында совет сугышчыларының Туганнар каберлегеннән билгесез солдат җәсәде Мәскәү Кремле дивары янында тантаналы рәвештә җирләнде. Бу көнне мәктәбебез укучылары авылыбыз һәйкәленә чәчәкләр куйды.

## *Ришвәтчелеккә урын юк!*

Мәктәптә һәр ел 8 нче декабрьдә бу темага кагылышлы сыйныф сәгатьләре уздырыла. Укучыларга хокуклар, гражданнарның бурычлары, ришвәтчелек турында белешмәләр бирелә. Ришвәтчелекнең тормышта нинди роль уйнаганын, нәтиҗәсе нинди булганын төшендерергә тырышабыз. Быел да шушы юнәлештәге конкурста катнашып, призлы урыннар да яуладык. Хәбибрахманова Хәнифә – җиңүче (рәсем), Закирова Ләйсән – призер (инша).



## *Конституция көне*

12 нче декабрьдә мәктәпнең укыту-тәрбия планы буенча Рәсәй конституциясе көне билгеләп үтелде. Бу дәрестә Конституциянең – дәүләтнең төп законы һәм Россиянең бөтен хокукый системасының нигезе икәнен аңлатабыз. Илебез шушы закон нигезендә яшәргә тиеш. Җәмгыятьтә халык тынычлыгы һәм татулык та шушы законга нигезләнгәнлеген белеп калалар мондый дәресләрдән.

## *Сәламәт туклану*



Үткән айда укучылар өчен дөрес туклану серләрен аңлатуга багышланган сыйныф сәгатьләре һәм атналыклар узды. Балаларга файдалы ризыкларга, дөрес итеп тукلануга өстенлек бирергә икәнлеге дә аңлатып үтелде. Сәламәтлекне саклау алымнары күрсәтелде. Дөрес туклану кеше организмын нормага сала, сәламәтлеген ныгыта, төрле авыруларга профилактика булып торганлыгы аңлатылды. Нинди ризыкта кайсы витаминнар күплеге, тәүлекнең кайсы вакытында нинди ризыкларга өстенлек бирергә кирәклеген дә сөйләштеләр.

Укучыларыбыз арасында бу темаларга рәсем конкурсы да уткәрелде. Бу хезмәтләр укучылар өчен эзсез калмаслар дип ышанасы килә.

***Камил Төхвәтуллин, VIсыйныф укучысы***

***/Безгә кунак килде/***

## *Олы кунаклардан киңәшләр*

Мәктәбебездә 9 нчы декабрь көнне узган конференциягә бик күп дәрәҗәле кунаклар килгән иде. Безнең хәбәрчеләр шуларның кайберләреннән интервью алып калды.

Беренче әңгәмәбез язучы-журналист, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан китап нәшрияты медиа-продюсеры, «Яңа исем» проекты авторы һәм җитәкчесе **Гөлүсә Закирова** белән булды.

***-Гөлүсә апа, сез журналистикага беренче адымны нидән ясадыгыз?***

- Беләсезме, кечерәк чакта газета-журналларга язасың бит. Ә бу инде журналистиканың беренче адымы санала. Әгәр кулыңа гонорар да бирсәләр, син инде каләм хакы алучы буласың. Ә без сезнең кебек вакытта каләм хаклары бирәләр иде балаларга. Мәктәпне тәмамлап тарих укытучысына укырга кергәч, икенче курстан “Сабантуй” балалар газетасына эшләргә чакыргалый башладылар. Шулай йөри торгач бардым, шунда төпләнеп тә калдым. Хәзергәчә менә журналистикада инде.

***- Сезнең берничә юнәлеш буенча эшләгәнегез билгеле. Үзегез өчен иң ошаган эш кайсысы?***

-Иң ошаган эш, иң яратканы – балалар басмаларында.Чөнки анда аларның күңел хәсиятләрен аңлап эшлисең. Чыннан да, мин төрле өлкәләрдә эшләдем: радиода да, журналларда да. Хәзер китап нәшриятендә сезнең кебек яшьләр белән эшлим. Кайда эшләсәм дә, сынатмаска тырышам. Язарга алындың икән, димәк, язарга кирәк. Менә, мәсәлән, диктофон куеп, яздырып, социаль челтәрләргә булса да куярга, мәкалә итеп әзерләп бирергә. Менә мин үзем бик яратам мәкаләләр язарга. Төп эшем шул дип уйлыйм.

***-Әле сез тарихны да өйрәнәсез дип беләбез. Бу юнәлеш белән кайчан кызыксына башладыгыз?***

- Тарих белән кызыксыну кечкенә вакытта ук уянды миндә. Без бит әби-бабаларыбызның кем булганын да белми идек. Иң башта үз нәселемнең тарихын торгызырга омтылдым. Бабаларымның мулла булганлыгын, аларның кайберләрен атып үтергәннәрен ишеткән идем. Әкеренләп шул хәлләргә кагылышлы документлар, бабайның фотосын таптык. Шуннан башланган эш, туган авылымның тарихын язу белән тәгәлләнде. Тора-бара башка авылларның тарихларын да язып чыктым. Архивларда тарихи документлар белән эшләү барышында моңа кадәр билгеле булмаган бик күп серләр ачыла.

Яшьләргә киңәшем шул: һәркем үзенен тарих китабын әшли ала, үзегезнең әби-бабайларыгыз, нәселегез турында. Шуны А4 форматында чыгарып степлер белән әләктереп куясыз да, китап язучыга әвереләсез. Мин, мәсәлән, эшне шуннан башладым.

**- Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Гөлүсә апа. Сезгә иҗади уңышлар теләп калабыз. һәм тагын да сезнең белән шундый очрашулар көтәбез.**

---



Шулай ук,тарих фәннәре докторы, Россия фәннәр академиясенең Тубыл фәнни станциясе өлкән фәнни хезмәткәре Дамир Мәүләви улы Исхаковка мөрәҗәгать иттек.

***- Дамир абый, Русиядә халык гомер бакый авыллары кешеләр хисабына арткан. Бу бит бүгенге көндә мөмкин түгел. Авылда соңгы елларда өлкән яшьтәгеләр генә калып барганын күзәтәбез. Авылларыбызны ничек яшәртеп булыр икән?***

- Монда сәясәт бер генә инде, матурым. Менә сез яшь булып үсеп җиткәч өйләнеп, кияүгә чыгып, әби-бабаларыгыз кебек һәрбер гаиләдә бишәр бала үстерсәгез, ул вакытта авыллар бетмәячәк. Ә вәзгыять бүгенге көндәге кебек калса, бик күп авыллар чынлап та, алдагы егерме биш, утыз ел эчендә юкка чыгачак.

***-2017 елдан бирле урыс булмаган телләрне каты кысу бара, татар теле, әдәбият дәресләре саны да нык кыскартылды. Туган телебезнең киләчәге нинди булыр икән?***

-Татар телен саклау бу бик авыр проблема булачак, кызганычка каршы. Дөресен әйткәндә, безнең телне берәү дә кисеп алмаган бит инде, тел үзебездә. Менә мин татар мәктәбендә укыдым. Шуңа да карамастан, рус телен күп урысларга караганда яхшырак беләм, инглизчә дә өйрәндем. Димәк, туган телне саклау, беренче чиратта, кешенең үзеннән тора. Әгәр дә мәктәпләрдә татар телен өйрәнү мөмкинлеге кими икән, гаиләдә, урамда күбрәк сөйләшергә кирәк туган телдә. Телне саклап калып була, әгәр дә үзен сөйләшсәң ул телдә; тел кулланыштан төшсә, ул вакытта ул бетәчәк.

Шуңа күрә хәзер, төп вазифа, телне саклау, безнең үзебезнең өстә, гаиләләрдә, аннан соң, һәрбер шәхестә. Мин уйлыйм, шуннан башлап, безнең тел юкка чыкмас, диеп.

Безнең татар теле– бик зур тарихка ия тел ул. Безнең телнең байлыгы искиткеч зур. Мәсәлән, революциягә кадәр генә дә, татар телендә ун меңнән артык исемдәге китап чыккан. Аларның тиражы илле миллионнан артып китә. Болардан тыш, әле газета-журналлар да чыккан бит татар телендә. Шуңа күрә безнең гасырлар дәвамында тупланып килгән милли телле мәдәни мирасыбыз бик зур. Менә шуларны исәпләгәндә, әгәр үзебез ана телебезне саклап үстерсәк,ул киләчәктә дә яшәячәк.

***- Әңгәмәгез һәм киңәшләрегез өчен рәхмәт, Дамир абый.***

***Әңгәмәне Зәйнәп Нурматова белән Самат Гафиятуллин алып бардылар***